**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» май 2015 ел **Чирмешән авылы** **№ 333**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында «Балаларны мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчалары) исәпкә кую һәм аларны күчерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»**

Мәктәпкәчә белем бирүне камилләштерү максатларында һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 10 мартындагы 1389/15 номерлы «Балаларны мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчалары) исәпкә кую һәм аларны күчерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының үрнәк формасын раслау турында» боерыгы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында «Балаларны мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчалары) исәпкә кую һәм аларны күчерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга (кушымта);
2. Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МУ башлыгына әлеге карар белән расланган Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының үтәлешен тәэмин итәргә.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Р.Ш. Долгополовага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Ф.М.Дәүләтшин**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитетының
2015 елның 27 маендагы
333 номерлы карары белән расланган

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында «Балаларны мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасынтормышка ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчалары) исәпкә кую һәм аларны күчерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең
АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында «Балаларны мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчалары) исәпкә кую һәм аларны күчерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Административ регламент) Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына мәктәпкәчә яшьтәге балаларны исәпкә кую һәм аларны күчерү тәртибен билгели (алга таба – муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәт алучылар - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә яшәүче, 1,5 яшьтән 7 яшькә кадәрге балаларның ата-аналары (башка законлы вәкилләре) булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары.

Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (алга таба – Оешма) чираттан тыш урнашу хокукына ия:
- судьялар балалары;
- прокурорларның һәм Тикшерү комитеты хезмәткәрләренең балалары;
- Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарның балалары һәм аларга тиңләштерелгән гражданнар категорияләре;
- оешмалары һәм төркемнәр эшчәнлеген ачыклау һәм булдырмау буенча махсус көчләр, Россия Федерациясенең Төньяк-Кавказ төбәге территориясендә контртеррористик операцияләр үткәрү буенча гаскәрләрнең (көчләрнең) берләштерелгән төркемнәренең һәлак булган (хәбәрсез югалган), үлгән, инвалид булган хезмәткәрләренең һәм хәрби хезмәткәрләренең балалары;
- Дагстан Республикасы территориясендә терроризмга каршы көрәштә турыдан-туры катнашкан һәм һәлак булган (хәбәрсез югалган), үлгән, хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә инвалид булган хәрби хезмәткәрләрнең һәм эчке эшләр органнары, дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-башкарма системасы хезмәткәрләренең балалары».

Оешмага беренче чиратта урнашу хокукына ия:

- инвалид балалар һәм әтисе яки әнисе инвалид булган балалар;
- күп балалы гаилә балалары;
- полиция хезмәткәренең балалары, шул исәптән хезмәт вазыйфаларын үтәү белән бәйле рәвештә алынган имгәнү яки башка җәрәхәтләре аркасында һәлак булган полиция хезмәткәренең балалары; хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә алынган һәм полициядә алга таба хезмәт итү мөмкинлеген төшереп калдырган имгәнү яки башка җәрәхәтләре аркасында полиция хезмәтеннән азат ителгән Россия Федерациясе гражданы балалары; хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә алынган сәламәтлеккә гарипләнү яки башка зыян килү аркасында, йә полициядә хезмәт итү чорында алынган, полициядә алга таба хезмәт итү мөмкинлеген төшереп калдырган авыру нәтиҗәсендә полициядән эштән киткәннән соң бер ел дәвамында вафат булган Россия Федерациясе гражданинының балалары; полиция хезмәткәре, Россия Федерациясе гражданы иждивениесендәге (элек булган) балалар;
- хәрби хезмәткәрләрнең балалары;
- махсус исемнәргә ия булган һәм җинаять-башкарма системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең федераль янгынга каршы хезмәтендә, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында хезмәт итүче, шул исәптән хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә алынган имгәнү яки башка зыян нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) хезмәткәрләрнең балалары; хезмәт үтү вакытында алынган авырулар нәтиҗәсендә вафат булганнарның; хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә алынган һәм алга таба хезмәт итү мөмкинлеген төшереп калдырган сәламәтлек өчен гарипләнү яисә башка зыян китерү аркасында эштән киткән; хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә алынган сәламәтлек өчен имгәнү яки башка зыян китерү аркасында йә хезмәт узу чорында алынган авыру нәтиҗәсендә, хезмәт үтү мөмкинлегеннән мәхрүм ителеп, хезмәттән китеп бер ел эчендә вафат булганнарның балалары; Россия Федерациясе гражданы, хезмәткәре иждивениесендәге (элек булган) балалар».

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә өстәмә мәктәпкәчә урыннарны үз исәпләренә булдырган оешма хезмәткәрләренең балалары, гамәлдәге законнар нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы катнашында төзелә торган дәүләт-хосусый партнерлык турындагы килешү шартлары нигезендә, төзелгән урыннарга тиң күләмдә, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар белән тәэмин ителәләр.

Игезәк балаларның берсен Оешмага җибәргән очракта, аларның икенчесе (һәм аннан соңы) әлеге оешмага чираттан тыш җибәрелә.

Бер гаиләдә яшәүче һәм гомуми яшәү урыны булган балалар мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча бертуган һәм (яки) сеңелләре белем алган оешмаларда укуга өстенлекле кабул итү хокукына ия.

Федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм закондагы норматив-хокукый актларда каралмаган башка нигезләр буенча ташламалар бирү рөхсәт ителми.

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль

районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ һәм әлеге Административ регламентның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән белем бирү оешмалары тарафыннан күрсәтелә.

1.4. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ урнашу урыны:

423100, Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Чирмешән авылы, Шешминская урамы, 4а.

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ эш графигы: 8.00.- 16.00.

1.5. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ белешмә телефоннары: (84396) 2-54-69, (84396) 2-54-30, (84396) 2-57-25.

1.6. Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ рәсми сайты адресы: edu.tatar.ru/cheremshan/cheremshan/roo.

1.7. Оешмаларның рәсми сайтларының урнашу урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, адреслары турында мәгълүмат 1 нче кушымтада күрсәтелгән.

1.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

- «-мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен бүлмәләрдә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмати стендлар ярдәмендә. Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Административ регламентның 1.1, 1.3, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) муниципаль хезмәт турында белешмәләрне үз эченә ала;
- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ рәсми сайтында;
- Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында күрсәтелгән кире элемтә формасы аша https://uslugi.tatar.ru/cei/feedback һәм техник ярдәм күрсәтү хезмәте телефоны буенча (8(843)5-114-115);
- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ һәм Оешмаларга телдән мөрәҗәгать иткәндә (телефон буенча яки шәхсән);
- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ язмача мөрәҗәгать иткәндә.

1.9. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла: Россия Федерациясе Конституциясе ("Российская газета", № 7, 21.01.2009);

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон ("Российская газета", N 303, 31.12.2012.);

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон» ("Российская газета", N 147, 05.08.1998);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон ("Российская газета", N 202, 08.10.2003);

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон ("Российская газета", N 95, 05.05.2006);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электрон рәвештә күрсәтелә торган беренче чираттагы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең җыелма исемлеген раслау турында» 2009 елның 17 декабрендәге 1993-р номерлы күрсәтмәсе ("Российская газета", N 247, 23.12.2009);

«Дәүләт йөкләмәсе (заказ) яисә муниципаль йөкләмә (заказ) урнаштырылган дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр һәм башка оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестрына кертелергә тиешле һәм электрон рәвештә күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2011 елның 25 апрелендәге 729-р номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте боерыгы ("Российская газета", N 93, 29.04.2011);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июнендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон» ("Российская газета", N 168, 30.07.2010);

«Инвалидларга дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» 1992 елның 2 октябрендәге 1157 номерлы РФ Президенты Указы ("РФ Президенты һәм Хөкүмәте актлары җыелышы", 05.10.1992, № 14, 1098 ст.);

«Күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 1992 елның 5 маендагы 431 номерлы РФ Президенты Указы ("Россия Федерациясе халык депутатлары һәм Россия Федерациясе Югары Советы съезды ведомостьлары", 14.05.1992, № 19, 1044 ст.);

«Полиция турында» 2011 елның 7 февралендәге 3-ФЗ номерлы Федераль закон ("Российская газета", N 25, 08.02.2011);

«Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль закон ("Российская газета", N 104, 02.06.1998);

Россия Федерациясе Прокуратурасы турында 1992 елның 17 гыйнварындагы 2202-1 номерлы закон ("Российская газета", N 39, 18.02.1992);

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» 1992 елның 26 июнендәге 3132-1 номерлы Россия Федерациясе Законы ("Российская газета", N 170, 29.07.1992);

«Чернобыль АЭС һәлакәте аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы ("Россия Федерациясе халык депутатлары һәм Россия Федерациясе Югары Советы съезды ведомостьлары ", 1991, N 21, ст. 699);

РФ Президентының "Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында хокук саклау хезмәте турында" 2003 елның 5 июнендәге 613 номерлы указы ("Российская газета", N 112, 11.06.2003);

2011 елның 1 августындагы «Татарстан Республикасында дәүләт-хосусый партнерлык турында» 50-ТРЗ номерлы ТР Законы («Татарстан Республикасы», № 156, 05.08.2011 ел);

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон («Российская газета», №3, 05.01.1995 ел);

"Кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренә социаль

гарантияләр һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2012 елның 30 декабрендәге 283-ФЗ номерлы Федераль закон ("Российская газета", № 3, 11.01.2013);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Террорчылыкка каршы операцияләрдә катнашучы һәм Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ төбәге территориясендә хокук тәртибен һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүче хәрби хезмәткәрләргә һәм федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр һәм компенсацияләр турында" 2004 елның 09 февралендәге 65 номерлы карары («Российская газета», №28, 13.02.2004 ел);

«Дагыстан Республикасы территориясендә террорчылыкка каршы көрәштә турыдан-туры катнашкан һәм һәлак булган (хәбәрсез югалган), хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә инвалид булган хәрби хезмәткәрләрнең һәм эчке эшләр органнары, дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-башкарма системасы хезмәткәрләренең гаилә әгъзаларын социаль яклау буенча өстәмә чаралар турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1999 елның 25 августындагы 936 номерлы карары («Российская газета», №169, 31.08.1999 ел);

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының "Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында" 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы боерыгы ("Российская газета", N 238, 23.10.2013);

Чирмешән муниципаль район Советының 2010 елның 7 августындагы 191 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы.

II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Балаларны мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) исәпкә алу һәм күчерү. | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 30 августындагы «Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 1014 номерлы боерыгы |
| 2.2. Башкарма хакимият | Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Чирмешән | «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 |

| | | |
|---|---|---|
| органының исеме | муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ һәм әлеге Административ регламентның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән белем бирү оешмалары тарафыннан күрсәтелә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар – Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «мәгариф бүлеге» МКУ хезмәткәрләре (алга таба - Вәкаләтле хезмәткәр).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар мөрәҗәгать итүчедән, әлеге Административ регламентта каралган мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрне һәм документларны һәм мәгълүматны алудан тыш, гамәлләр, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле һәм бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле килештерүләрне башкаруны таләп итәргә хокуклы түгел. | елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе булып баланы мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмасына (балалар бакчасы) күчерү тора. | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 30 августындагы «Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 1014 номерлы боерыгы |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә | Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:<br>- Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында гариза тутырган яки | |

| | | |
|---|---|---|
| катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып | Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ кәгазьдә гаризаны шәхсән биргәннән соң исәпкә кую өлешендә;<br>- балаларны оешмага күчерү өлешендә - Мөрәҗәгать итүче белән Оешма арасында килешү төзелгәннән бирле. | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең тулы исемлеге, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Баланы исәпкә алу өчен гариза бирүченең гаризасын тутырганда кирәкле мәгълүматлар исемлеге:<br>- баланың фамилиясе, исеме,атасының исеме;<br>- баланың туу датасы;<br>- туу турында таныклык белешмәләре;<br>- фактта яшәү урыны (адрес);<br>- әнисе, әтисе яки законлы вәкилләренең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, электрон почта адреслары, элемтә өчен телефон номеры;<br>- ата-ана (законлы вәкил) шәхесен таныклаучы документ белешмәләре;<br>- белем бирү оешмасына баланы кабул итү буенча ташламалар булуы турында белешмәләр;<br>- баланың сәламәтлеге буенча ихтыяҗы;<br>- бер теләгән оешма;<br>- төркемдә теләгән тәрбия һәм укыту теле;<br>- баланы Оешмага керүнең теләгән датасы;<br>- теләгән Оешмада урыннар булмаганда, башка балалар бакчасы тәкъдименә ризалык/ризасызлык.<br>2. Баланы Оешмага күчерү өчен кирәкле документлар исемлеге (Мөрәҗәгать итүче тарафыннан Оешмага шәхси мөрәҗәгать иткәндә бирелә):<br>- оешма җитәкчесе исеменә әти-әниләрнең (законлы вәкилләрнең) | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 30 августындагы «Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 1014 номерлы боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| | язма гаризасы;<br>- билгеләнгән үрнәктәге медицина бәяләмәсе (сәламәтлек саклау учреждениеләре тарафыннан бирелә);<br>- баланың ата яки анасының (законлы вәкилләренең) шәхесен таныклаучы документ;<br>- психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсе (баланы компенсацияләүче һәм катнаш юнәлештәге төркемнәргә керткәндә таләп ителә, психологик-медик-педагогик комиссия тарафыннан бирелә) | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны бирү тәртибе; карамагында әлеге документлар булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ташламаларны раслаучы документлар:<br>- күп балалы гаилә балалары;<br>- Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнар балалары;<br>- инвалид-балалар;<br>- әти яки әнисе инвалид булган гаиләләр.<br>Документлар социаль яклау территориаль органнары тарафыннан бирелә. | |
| 2.7. Муниципаль | Исәпкә кую өлешендә | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | - Оешмага кабул ителә торган балаларның максималь яшеннән баланың яше артык булуы.<br>Оешмага керү өлешендә:<br>- «Электрон балалар бакчасы» системасында баланы Оешмага җибәрү турында мәгълүмат булмау | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Исәпкә кую өлешендә:<br>- бала туу турында таныклык мәгълүматларын идентификацияләү процедурасына комачаулаучы дөрес булмаган (җитәрлек булмаган) мәгълүматларны бирү;<br>- Оешмага кабул ителә торган балаларның максималь яшеннән баланың яше артык булуы.<br>- теләгән тәрбия һәм укыту теле телəгән Оешмадагы тәрбия һәм укыту теленә туры килмәве.<br>Оешмага керү өлешендә:<br>- «Электрон балалар бакчасы» системасында баланы Оешмага җибәрү турында мәгълүмат булмау;<br>- баланың Оешмага йөрүенә медицина ягыннан каршылыклар булу;<br>- муниципаль хезмәт алудан баш тарту турында ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасы | «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон,<br>Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 30 августындагы «Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 1014 номерлы боерыгы |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт бушлай бирелә | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәткә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Шәхси кабул итүне көтү вакыты 15 минуттан да артмаска тиеш. Әгәр хезмәт пенсионерларга, инвалидларга күрсәтелә икән, киләсе мөрәҗәгать итүченең көтү (хезмәт күрсәтү) вакыты 30 минутка кадәр озайтылырга мөмкин. Мөрәҗәгать иткән барлык затларны кабул итү эш көне тәмамланырга 1 сәгатьтән дә соңга калмыйча тәэмин ителергә тиеш | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең запросын һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан | Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ мөрәҗәгать итүченең шәхси мөрәҗәгатендә исәпкә кую турындагы гаризаны теркәү гариза бирүченең Административ регламентның III бүлегендә каралган тәртиптә мөрәҗәгать иткән | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтелә торган хезмәтне теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | мизгелдән 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Баланы Оешмага кабул итү турында гаризаны теркәү гариза бирүче Административ регламентның III бүлегендә каралган тәртиптә мөрәҗәгать иткән мизгелдән 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтү биналарына таләпләр | Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган муниципаль хезмәт турында мәгълүмати стендлар урнаштырыла.<br>Бинаның фасад өлешендә муниципаль мәгариф идарәсе органы исеме турында мәгълүмат урнаштырыла.<br>Кабул итүне көтү өчен гариза бирүчеләргә документларны рәсмиләштерү өчен урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырылган урыннар бирелә.<br>Бина санитар кагыйдәләр һәм нормалар нигезендә җиһазландырылырга тиеш. | «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июнендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | - документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>- муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан башкарылган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын бозуга карата прецедентларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булуы | «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июнендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.16. Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтләр электрон рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында күрсәтелә (https://uslugi.tatar.ru) | «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июнендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон |

## III. Административ процедуралар

Муниципаль хезмәт күрсәтүдә
эзлекле гамәлләр тасвирламасы

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- исәпкә кую (исәпкә кую өчен гаризаны «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасында (алга таба – Система) теркәү);
- Оешмага җибәрү;
- Оешмага керү.

3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү блок-схемасы 3 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.3. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр үткәрү

Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ шәхсән, телефон аша һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Вәкаләтле хезмәткәр мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация бирә һәм кирәк булганда гариза тутыруда ярдәм күрсәтә.

3.4.Исәпкә кую.

3.4.1. Оешмага урнашу буенча исәпкә кую өчен гаризаны ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан тутыру гамәлгә ашырыла:

- Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (https://uslugi.tatar.ru/);

- Дәүләт хезмәтләре бердәм порталы аша (https://beta.gosuslugi.ru/);

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» муниципаль бюджет учреждениесенә шәхси мөрәҗәгать иткәндә.

Гаризалар кабул итү һәм аны Системада теркәү ел дәвамында башкарыла. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә мөрәҗәгать иткәндә әлеге гаризаны Системага Вәкаләтле хезмәткәр кертә, ул Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ боерыгы белән билгеләнә. Системага мәгълүматларны кертү Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән мизгелдән 1 эш көне эчендә башкарыла.

Гаризаны тутырганда ата-аналар (законлы вәкилләр) персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирә (Административ регламентка 2 нче кушымта).

3.4.2. Исәпкә алу өчен гариза биргәндә, Система тарафыннан туу турындагы таныклыкның дөреслеген тикшерү гамәлгә ашырыла. Әгәр мәгълүматлар дөрес түгел, йә юк икән, системада гаризага «Документларны раслау» статусы бирелә. Бу очракта Мөрәҗәгать итүчегә документларны раслау өчен Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУнең кабул итү сәгатьләренә килергә кирәк. Документларны Мөрәҗәгать итүче раслаганнан соң, Вәкаләтле хезмәткәр документлар расланганнан соң 1 эш көне эчендә гаризага Системада гариза биргән көннән «Теркәлгән» статусын бирә.

3.4.3. Законлы вәкил (опекун, попечитель) гариза биргән очракта, системада гариза «Опека (попечительлек) раславы» статусын ала.

Бу очракта Гариза бирүчегә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә опека (попечительлек) турындагы документларны раслау өчен килергә кирәк. Документларны Гариза бирүче раслаганнан соң, Вәкаләтле хезмәткәр документлар расланганнан соң 1 эш көне эчендә гаризага «Теркәлгән» статусын гариза биргән көннән бирә.

3.4.4. Гариза бирүче Оешмага чираттан тыш, беренче чиратта, өстенлекле керү хокукына ия булса, аның гаризасына «Документларны раслау» статусы бирелә. Мөрәҗәгать итүчегә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә ташламаны раслый торган документның оригиналын, шулай ук аның күчермәсен тапшырырга кирәк, түбәндәге ташламаларны раслый торган документлардан тыш:

күп балалы гаилә балалары;

Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнар балалары;

инвалид балалар;

әти яки әнисе инвалид булган гаиләләр.

Әлеге ташламалар исемлеге Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмати системасына запрос белән, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан бирелгән гаризалар буенча район мәгариф бүлегенә ташламаларны раслауга шәхси визитны төшереп калдыру өчен автомат рәвештә раслана.

Ташламаны раслаучы документ күчермәсе Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесендә саклана.

Гариза бирүче тарафыннан документлар расланганнан соң, Вәкаләтле хезмәткәр гаризага гариза биргән көннән алып 1 эш көне эчендә «Теркәлгән» статусын бирә.

Гариза бирүчедә ташламалар булуын раслау гына кирәк булса, гариза ташламалар раслаганчы Системада гомуми нигезләрдә теркәлә.

Билгеләнгән ташламаның гамәлдә булу срогы чыккач, Мөрәҗәгать итүчегә Оешмага чираттан тыш, беренче чираттагы, өстенлекле кабул итү хокукын расларга кирәк.

3.4.5. Теркәлгән гаризага индивидуаль идентификация номеры бирелә. Гариза статусын һәм чиратлылыкта Мөрәҗәгать итүче урынын Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatar.ru, бала туу турындагы таныклык (серия һәм номер) яисә гаризаның индивидуаль идентификация номеры мәгълүматлары буенча, Дәүләт хезмәтләренең бердәм порталы https://beta.gosuslugi.ru/ аша, шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф

бүлеге» МКУ аша кабул итү сәгатьләрендә шәхси мөрәҗәгать иткәндә яисә телефон аша тикшерергә мөмкин.

Исәпкә куелганда Гариза бирүче баланы күчерү өчен гаризада бер Оешманы күрсәтергә хокуклы.

Гаризага индивидуаль идентификацион номер бирелгәннән соң, гариза бирүче гаризасы буенча теләгән Оешманы алыштыру рөхсәт ителә. Мөрәҗәгать итүче теләгән оешманы алмаштыруга теләгән оешманың урнашу урыны буенча мәгариф белән идарә итү органнарына гариза бирә. Исәпкә кую датасы шул ук вакытта саклана.

Шулай ук мөрәҗәгать итүче теләгән оешманы дәүләт хезмәтләренең бердәм порталы аша гаризада үзгәртә ала https://beta.gosuslugi.ru/.

Вәкаләтле хезмәткәр, гариза биргән көннән алып, 5 эш көне эчендә, җибәрелгән хаталарны (баланың исем-фамилиясендә, туу датасында, туу турында таныклык реквизитларында һ.б., исәпкә кую датасыннан башка) бетерү максатында, граждан гаризасына кирәкле төзәтмәләр кертергә хокуклы. Әлеге вакыт узганнан соң үзгәрешләр кертү Система администраторы тарафыннан вәкаләтле хезмәткәр гаризасы буенча гамәлгә ашырыла.

Баласы 8 яшькә җиткән гариза бирүченең исәпкә кую турындагы гаризасы вәкаләтле хезмәткәр тарафыннан «архив» статусына күчерелә.

Элек исәпкә куелган баланы буш урыннар булган авыл Оешмасына исәпкә кую һәм урнаштыру рөхсәт ителә. Гариза авыл Оешмасы урнашкан урын буенча мәгариф идарәсе органнарына тапшырыла. Беренчел гариза буенча теләгән Оешмага чират саклана.

Яңа Оешмалар системага Вәкаләтле хезмәткәр гаризасы буенча Система администраторы тарафыннан кертелә.

3.4.6. Комплеклтлау башланганчы 30 календарь көн алдан Оешмалар Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ чираттагы уку елында балаларның һәр яшь категориясе буенча төркемнәрдә (план группалары) буш урыннар саны турында белешмәләрне раслауга тапшыралар.

Оешмаларны чираттагы уку елына туплау чираттагы уку елына төркемнәр һәм аларда буш урыннар расланган саны нигезендә агымдагы елның 1 июненнән 31 августына кадәр башкарыла. Системада балаларның яше агымдагы елның 1 сентябренә исәпләнә.

Уку елы дәвамында буш урыннар булганда Оешмаларны Административ регламентның 3 пунктында каралган тәртип нигезендә тулыландыралар.

Оешмаларны комплектлаганда, Системада балаларның яшен исәпләүне үзгәртү кирәк булганда, агымдагы елның 1 сентябреннән 31 декабренә кадәр, муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан ТР Мәгариф һәм фән министрлыгына үтенечнамә юллана. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән килештереп, өстәмә комплектлау датасы билгеләнә, аның көнендә системаның администраторы балаларның яшен исәпләүне алмаштыра.

Туплау нәтиҗәләре турында гражданнарга мәгълүмат бирү Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән башкарыла.

Оешмаларны комплектлаганда гражданнар гаризасы вәкаләтле хезмәткәрләр тарафыннан бер эш көненнән артык эшкәртелә алмый.

3.5. Оешмага җибәрү һәм кабул итү.

3.5.1. Мөрәҗәгать итүче чираты якынлашканда һәм теләгән Оешмада тиешле яшь төркемендә урын булган очракта, гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелде» статусы бирелә. Әлеге статусны бирү турында хәбәр Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында, Дәүләт хезмәтләренең бердәм порталында күрсәтелә.

3.5.2. Мөрәҗәгать итүче «Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә җибәрелгән» статусын алганнан соң 30 календарь көнгә кадәр баланы кабул итүне раслау өчен оешмага килергә тиеш.

3.5.3. Оешма җитәкчесе Гариза бирүчедән баланы алу турында гариза белән мөрәҗәгать иткән мизгелдән 1 эш көне эчендә гаризага Системада «Килешү төзү» статусын бирә.

Мөрәҗәгать итүче «Килешү төзү» статусы бирелгән көннән бер ай эчендә килешү төзү өчен Оешмага килергә тиеш.

3.5.4. Әгәр Мөрәҗәгать итүчене бала җибәрелгән Оешма канәгатьләндермәсә, Гариза бирүче тарафыннан әлеге Оешмага җибәрүдән баш тарту рәсмиләштерелә. Гаризага «теркәлгән» статусы бирелә. Исәпкә кую датасы үзгәрми.

Тәкъдим ителгән оешмага җибәрүдән баш тарту Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ шәхси мөрәҗәгатендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ тарафыннан билгеләнгән форма буенча язмача рәсмиләштерелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән мизгелдән 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Системада гаризага «Теркәлгән» статусы бирү, тәкъдим ителгән Оешмага җибәрүдән баш тарту.

Теләгән укырга керү датасын Гариза бирүче җибәрүдән баш тарту турында мөрәҗәгать иткән көннән дә иртәрәк булмаган датага алыштыру башкарыла

3.5.5. Гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелгән» статусын биргәннән соң гариза бирүче оешмага килмәгән очракта, Административ регламентның 3.5.2 п. белән билгеләнгән срокта мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү туктатыла. Оешма җитәкчесе Системадагы гаризага «Килмәгән» дигән статус бирә.

3.5.6. Әгәр гариза бирүче үзенең хезмәт алу теләген раслый икән, гаризага «Теркәлгән» статусы бирелә. Исәпкә кую датасы үзгәрми. Әгәр мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартса, гаризага «Хезмәт күрсәтүдән баш тарткан» статусы бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүне раслау яки баш тарту Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ тарафыннан билгеләнгән формада яшәү урыны буенча мәгариф идарәсе органнарына шәхси мөрәҗәгать иткәндә язмача рәсмиләштерелә.

Раслау вакытында теләгән укырга керү датасын Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көннән дә иртәрәк булмаган датага алыштыру башкарыла муниципаль хезмәт күрсәтүгә ихтыяҗны күрсәтеп.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән мизгелдән 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гаризага Системада «Теркәлгән» яки «Хезмәт күрсәтүдән баш тарту» статусын бирү.

3.6. Оешмага керү.

3.6.1. Ата-аналар (законлы вәкилләр) белән килешү төзегәннән соң Оешма җитәкчесе 1 эш көне дәвамында Системага килешү реквизитларын кертә һәм Системада гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә кабул ителгән» статусын бирә.

Баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләве гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә кабул ителгән» статусы бирелгән көннән билгеләнә.

3.6.2. Гариза бирүче килешү төзү өчен билгеләнгән вакытка килмәгән очракта, оешма җитәкчесе гаризага «Килмәгән» статусын бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар «Шартнамә төзү» статусы бирелгән көннән бер айлык срок исәпләнгәннән соң 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

3.6.3. Әгәр Гариза бирүче үзенең хезмәт алу теләген раслый икән, гаризага «Теркәлгән»статусы бирелә. Исәпкә кую датасы үзгәрми.

Әгәр мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартса, гаризага «Хезмәт күрсәтүдән баш тарткан» статусы бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүне раслау яки баш тарту Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ тарафыннан билгеләнгән формада яшәү урыны буенча мәгариф идарәсе органнарына шәхси мөрәҗәгать иткәндә язмача рәсмиләштерелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән мизгелдән 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Системадагы гаризага «Теркәлгән» яки «Хезмәт күрсәтүдән баш тарту» статусы бирү.

Раслау вакытында теләгән укырга керү датасын Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көннән дә иртәрәк булмаган датага алыштыру башкарыла муниципаль хезмәт күрсәтүгә ихтыяҗны күрсәтеп.

3.6.4. Компенсацияләүче һәм сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемнәргә гаризаларында сәламәтлек буенча ихтыяҗлары күрсәтелгән балалар җибәрелә.

Баланы билгеле бер вакытка (вакытлыча, медицина бәяләмәсе яки психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсе нигезендә) компенсацияләүче яки сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемгә җибәргән очракта, юнәлештә «вакытлыча укырга керү» дигән билге куела.

